КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 июль г.Казань № 634

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 гыйнвар, 29 нчы; 2016 ел, 2 сентябрь, 612 нче; 2017 ел, 21 март, 161 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1115 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1230 нчы; 2019 ел, 3 май, 376 нчы; 2019 ел, 3 июнь, 460 нчы; 2020 ел, 3 март, 165 нче; 2020 ел, 5 октябрь, 905 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның II бүлегендәге тугызынчы абзацында «16 983» саннарын «16 982» саннарына алмаштырырга;

Программаның V бүлегендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән капиталь ремонтка кертемнең минималь күләменнән чыгып формалаштырылган сумма чикләрендә капиталь ремонт фонды акчасы һәм Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган, дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча түбәндәге хезмәтләр күрсәтүне һәм (яки) эшләр башкаруны гамәлгә ашыру:

1) электр-, җылылык-, газ-, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру;

2) лифтларны ремонтлау, алыштыру, модернизацияләү, лифт шахталарын, машина һәм блок урыннарын ремонтлау;

3) түбә ремонтлау, җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау;

4) күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау;

5) фасадны җылыту һәм ремонтлау;

6) коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпкә ала торган күмәк (гомумйорт) приборларны һәм мондый ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) кулллануны җайга салу һәм идарә узелларын кую һәм (яки) алыштыру;

7) коммуналь ресурсларны һәм коммуналь хезмәтләрне кулллануны исәпкә алуның автоматлаштырылган мәгълүмат-үлчәү системаларын урнаштыру;

8) күпфатирлы йортның фундаментын, шулай ук күтәреп торучы диварларны, түшәмә плитәләрен, балкон һәм башка плитәләрне, күтәреп торучы баганаларны һәм башка әйләнедереп алган күтәреп торучы конструкцияләрне ремонтлау һәм (яки) ныгыту;

9) төзелеш контролен гамәлгә ашыру;

10) проект документларына дәүләт экспертизасын әзерләү һәм үткәрү (проект документларын әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булган очракта), капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә тикшерү үткәрү;

11) күпфатирлы йорттагы подъездларны, күпфатирлы йорттагы аерым милекчеләрнеке булмаган һәм бүлмәләр милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән башка бүлмәләрне ремонтлау;

12) вентиляция каналларын һәм төтен юлларын ремонтлау;

13) күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керми торган, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керә торган конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда ремонтлана (алыштырыла) торган конструкцияләр һәм инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән мөлкәт өлешен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү;

14) 2014 елның 1 июненә кадәр куелган (алыштырылган) күпфатирлы йортлардагы коммуналь ресурсларны куллану исәбен алуның күмәк (гомумйорт) җайланмаларын кую (алыштыру).»;

Программага кушымтаның «2022 ел» бүлегендәге 126 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 26 июнь, 437 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1103 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1229 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган, дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлегенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 21 июль, 634 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган, дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге

1. Электр-, җылылык-, газ-, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру.
2. Лифтларны ремонтлау, алыштыру, модернизацияләү, лифт шахталарын, машина һәм блок урыннарын ремонтлау.
3. Түбә ремонтлау, җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау.
4. Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау.
5. Фасадны җылыту һәм ремонтлау.
6. Коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпкә ала торган күмәк (гомумйорт) приборларны һәм мондый ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) кулллануны җайга салу һәм идарә узелларын кую һәм (яки) алыштыру.
7. Коммуналь ресурсларны һәм коммуналь хезмәтләрне кулллануны исәпкә алуның автоматлаштырылган мәгълүмат-үлчәү системаларын урнаштыру.
8. Күпфатирлы йортның фундаментын, шулай ук күтәреп торучы диварларны, түшәмә плитәләрен, балкон һәм башка плитәләрне, күтәреп торучы баганаларны һәм башка әйләнедереп алган күтәреп торучы конструкцияләрне ремонтлау һәм (яки) ныгыту.
9. Төзелеш контролен гамәлгә ашыру.
10. Проект документларына дәүләт экспертизасын әзерләү һәм үткәрү (проект документларын әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булган очракта), капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә тикшерү үткәрү.
11. Күпфатирлы йорттагы подъездларны, күпфатирлы йорттагы аерым милекчеләрнеке булмаган һәм бүлмәләр милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән башка бүлмәләрне ремонтлау.
12. вентиляция каналларын һәм төтен юлларын ремонтлау.
13. Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керми торган, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керә торган конструкцияләрне һәм

инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда ремонтлана (алыштырыла) торган конструкцияләр һәм инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән мөлкәт өлешен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү.

---